ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09 июня 2020 ел № 2769

Яр Чаллы шәһәренең күчемсез муниципаль милек объектларыннан файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү методикасын раслау турында

Файдаланылмый торган муниципаль милекне ачыклау, аны хуҗалык әйләнешенә кертү һәм (яки) билгеләнеше буенча файдаланылмаган күчемсез муниципаль милекне ачыклау максатында, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 4 октябрендәге 25/5 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану, идарә итү һәм эш йөртү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең күчемсез муниципаль милек объектларыннан файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү методикасын (алга таба-Методика) кушымтада каралганча расларга.

2. Яр Чаллы шәһәренең муниципаль учреждениеләренә һәм муниципаль предприятиеләренә ел саен Башкарма комитетның тармак (функциональ) органнарына үзләренә оператив идарә, хуҗалык алып бару хокукында беркетелгән күчемсез муниципаль милек объектлары һәм Методика нигезендә, әлеге объектлардан нәтиҗәле файдалану күрсәткече зурлыклары турында мәгълүматлар тапшырырга.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы С.Ә. Ситдыйковка, Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 9 июнендәге
2769 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең күчемсез муниципаль милек объектларыннан
файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү
методикасы

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Методика муниципаль учреждениегә оператив идарә хокукында, муниципаль предприятиегә хуҗалык алып бару хокукында беркетелгән Яр Чаллы шәһәренең күчемсез муниципаль милек объектларыннан, шулай ук муниципаль казна милкеннән, җир участокларыннан тыш (алга таба - күчемсез милек объектлары) файдалану нәтиҗәлелеген бәяләүне үткәрү тәртибен һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитет тармак (функциональ) органнарының (алга таба - тармак органнары), муниципаль учреждениеләрнең, муниципаль предприятиеләрнең үзара хезмәттәшлеген гамәлгә ашыру тәртибен билгели.

2. Әлеге Методиканың максатлары өчен күчемсез милек объектларыннан нәтиҗәле файдалану дигәндә түбәндәгеләр аңлашыла:

- муниципаль учреждение, муниципаль предприятие эшчәнлегенең уставта билгеләнгән предметы, максатлары һәм төрләре нигезендә һәм билгеләнеше буенча күчемсез милектән файдалану.;

- хокукый нигезсез өченче затлар тарафыннан күчемсез милек объектларыннан файдалану фактлары булмау;

- күчемсез милек объектларыннан файдаланмау фактлары булмау;

- күчемсез милек объектларыннан файдаланудан алынган керемнәрнең уңай динамикасы.

3. Күчемсез милек объектларыннан файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү күчемсез милек объектлары белән идарә итү һәм эш йөртү нәтиҗәлелеген күтәрү, алардан файдаланудан һәм әлеге объектлар белән идарә итү механизмнарын оптимизацияләүдән керемнәрне арттыру максатында гамәлгә ашырыла.

2 бүлек. Күчемсез милек объектларыннан файдалану
нәтиҗәлелеген бәяләүне үткәрү тәртибе

4. Муниципаль учреждениеләр, муниципаль предприятиеләр ел саен, күчемсез милектән файдалану һәм аның белән идарә итү нәтиҗәлелеген бәяләүне үткәрү өчен, хисап елыннан соң килә торган елның беренче апреленнән дә соңга калмыйча, тармак органнарына түбәндәге мәгълүматларны тапшыралар:

1) 1 нче кушымтада каралган форма буенча күчемсез милек объекты турында мәгълүматлар;

2) 2 нче кушымтада каралган форма буенча арендатор, ссуда алучы, күчемсез милек объектының субарендаторы турында мәгълүматлар;

3) 3 нче кушымтада каралган форма буенча муниципаль казна, бюджет, автономияле учреждениеләр тарафыннан күчемсез милек объектларыннан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең зурлыклары;

4) 4 нче кушымтада каралган форма буенча муниципаль казна, унитар предприятиеләр тарафыннан күчемсез милек объектларыннан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең зурлыклары.

Әлеге пунктның 1-2 пунктчаларында күрсәтелгән мәгълүматлар, хисап елыннан соң килә торган елның беренче гыйнварына торышы буенча, һәр күчемсез милек объектына карата тапшырыла.

Әлеге пунктның 3 пунктчасында күрсәтелгән мәгълүматлар, хисап елыннан соң килә торган елның беренче гыйнварына торышы буенча, муниципаль учреждениеләргә беркетелгән күчемсез милек объектларының барлык җыелмасына карата тапшырыла.

Әлеге пунктның 4 пунктчасында күрсәтелгән мәгълүматлар, хисап елыннан соң килә торган елның беренче гыйнварына торышы буенча, муниципаль предприятиеләргә беркетелгән күчемсез милек объектларының барлык җыелмасына карата тапшырыла.

5. Муниципаль учреждениеләр һәм муниципаль предприятиеләр тарафыннан күчемсез милек объектларыннан максатчан файдалану күрсәткечләре, күчемсез милек объектларыннан файдалану нәтиҗәлелегә күрсәткечләре түбәндәге тәртиптә билгеләнә:

1) күчемсез милек объектларыннан максатчан файдалану күрсәткече түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$N = \frac{S_{общ.} - S_{исп.}}{S_{общ.}} *100\%,$$ монда:

$S_{общ.}$ – күчемсез милек объектының гомуми мәйданы;

$S_{исп.}$ – күчемсез милек объектының формула буенча исәпләнгән файдаланыла торган мәйданы:

$$S_{исп.} = S_{уд.} + S_{п.},$$ монда:

$S_{уд.}$ - устав эшчәнлеген алып бару өчен муниципаль учреждение, муниципаль предприятие тарафыннан файдаланыла торган күчемсез милек объектының мәйданы;

$S_{п.}$ – аренда, түләүсез файдалану шартнамәләре буенча өченче затларга файдалануга бирелгән күчемсез милек объектының мәйданы.

Бер бүлмәне төрле эш режимнары булган берничә өченче затлар файдаланганда, бүлмәнең мәйданы $S_{исп.}$ га бер генә тапкыр кертелә.

Күчемсез милек объектыннан максатчан файдалану күрсәткечен исәплəгәндә күчемсез милек объектының мәйданы өченче затларга бирелмәгән гомуми файдаланудагы бүлмәләр (коридорлар, тамбурлар, баскыч урнашкан урыннар, лифт шахталары, баскычлар) мәйданын исәпкә алмыйча кулланыла.

Күчемсез милек объектының бер өлеше файдаланылмый дип таныла һәм тармак органы тарафыннан, N түбәндәге зурлыкларыннан чыгып, күчемсез милек объектыннан файдалану нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләү гамәлгә ашырыла:

20 % – $S_{общ.} < 200$ кв.м булган очракта;

10 % – $S_{общ.} \geq 200$ кв.м, но $< 500$ кв.м булган очракта;

5 % – $S_{общ.} \geq 500$ кв.м булган очракта;

2) муниципаль учреждениеләр һәм муниципаль предприятиеләр тарафыннан күчемсез милек объектларыннан файдалану нәтиҗәлелегенең күрсәткече түбәндәге ысулларның берсе буенча билгеләнә: чагыштырма, керем, аналитик.

Чагыштырма метод күчемсез милек объектларыннан файдалану нәтиҗәлелеген билгеләүнең гомуми методы булып тора, аның кысаларында Яр Чаллы шәһәре милкендәге, Татарстан Республикасының башка муниципаль берәмлекләре милкендәге, Татарстан Республикасы милкендәге аналогик объектлардан файдаланып, аерым күчемсез милек объектыннан файдалануны чагыштыруга нигезләнгән бер яки аннан күбрәк методлар кулланыла.

Керем методы күчемсез милек объектларыннан файдаланудан керемнәр күләмен, аларны карап тотуга киткән чыгымнар белән бәяләүне үткәрүгә нигезләнә.

Аналитик метод күчемсез милек объектларыннан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең тәкъдим ителгән зурлыкларын анализлаудан тора.

6. Муниципаль учреждениеләр һәм муниципаль предприятиеләр җитәкчеләре тәкъдим ителгән мәгълүматның дөреслеге өчен персональ җаваплылык тоталар.

7. Тармак органнары ел саен, хисап елыннан соң килә торган елның беренче маена кадәр гамәлгә ашыралар:

1) муниципаль учреждениеләр һәм муниципаль предприятиеләр тарафыннан бирелгән мәгълүматларны җыюны һәм анализлауны;

2) Методиканың 5 пунктында каралган тәртиптә, муниципаль учреждениеләр һәм муниципаль предприятиеләр тарафыннан күчемсез милек объектларыннан максатчан файдалану күрсәткечләрен, күчемсез милек объектларыннан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен билгеләү;

3) ачыкланган файдаланылмый торган күчемсез милек объектлары исемлеген формалаштыру;

4) Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенә ачыкланган файдаланылмый торган күчемсез милек объектын хуҗалык әйләнешенә кертү, күчемсез милек объектыннан файдалану нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләү;

5) 5 нче кушымтада каралган форма буенча муниципаль учреждениеләр тарафыннан күчемсез милек объектларыннан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең җыелма зурлыкларын формалаштыру;

6) 6 нчы кушымтада каралган форма буенча муниципаль предприятиеләр тарафыннан күчемсез милек объектларыннан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең җыелма зурлыкларын формалаштыру;

7) Методиканың 5 пункты нигезендә билгеләнгән нәтиҗәләрне күрсәтеп, күчемсез милек объектларыннан файдаланмауга, нәтиҗәсез файдалануга китергән сәбәпләрнең аналитик язмасын әзерләү;

8) Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенә, әлеге пунктның 2.7 пунктчаларында күрсәтелгән мәгълүматны теркәп, ведомство буйсынуындагы һәр оешмага карата, муниципаль учреждениеләр һәм муниципаль предприятиеләр тарафыннан бирелгән күчемсез милек объектлары турында мәгълүматлар бирү.

8. Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе, хисап елыннан соң килә торган елның беренче маена кадәр, 7 нче кушымтада каралган форма буенча күчемсез казна милке объектларыннан файдалану нәтиҗәлелеген бәяләүне үткәрә һәм, хисап елыннан соң килә торган елның беренче июненә кадәр срокта тармак органнарының аналитик язмалары мәгълүматларын карап тикшергәннән соң, Башкарма комитет Җитәкчесенә күчемсез милек объектларыннан файдалану нәтиҗәлелеген арттыру, ачыкланган файдаланылмый торган күчемсез милек объектларын хуҗалык әйләнешенә кертү буенча тәкъдимнәр кертә.

9. Муниципаль учреждениеләрнең һәм муниципаль предприятиеләрнең җитәкчеләре тарафыннан бирелгән мәгълүматларның дөреслеген контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе гамәлгә ашыра.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе                                        Г.К. Әхмәтова

Яр Чаллы шәһәренең күчемсез
милек объектларыннан файдалану
нәтиҗәлелеген бәяләү методикасына
1 нче кушымта

«___» _________ 20____ елга торышы буенча

(оешманың (объектның балансча тотучысының) тулы исеме)

күчемсез милек объекты турында мәгълүмат

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Кадастр номеры | |
| 2. | Исеме (хокукны дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклык яисә техник документ нигезендә күрсәтелә) | |
| 3. | Урнашу урыны | |
| 4. | Билгеләнеше | |
| 5. | Хокук билгели торган документ | |
| 6. | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең объектка милек хокукын дәүләт теркәвенә алу датасы һәм номеры | |
| 7. | Оператив идарә, хуҗалык алып бару хокукын дәүләт теркәвенә алу датасы һәм номеры | |
| 8. | Баланс бәясе, сум | |
| 9. | Калдык бәя, сум | |
| 10. | Физик хәл тасвирламасы (канәгатьләнерлек, канәгатьләнмәслек) | |
| 11. | Гомуми мәйданы, кв.м (файдалы мәйданны һәм гомуми файдаланудагы бүлмәләр мәйданын күрсәтеп) | |
| 12. | Балансча тотучы тарафыннан биләнә торган гомуми мәйдан, кв.м (файдалы мәйданны һәм гомуми файдаланудагы бүлмәләр мәйданын күрсәтеп), (өченче затларга арендага яки түләүсез файдалануга бирелгән мәйданнардан тыш) | |
| 13. | Аренда, түләүсез файдалану хокукында өченче затлар тарафыннан биләнә торган гомуми мәйдан, кв.м (файдалы мәйданны һәм гомуми файдаланудагы бүлмәләр мәйданын күрсәтеп) | |
| 14. | Буш (файдаланылмый торган) бүлмәләр мәйданы, кв.м (файдалы мәйданны һәм гомуми файдаланудагы бүлмәләр мәйданын күрсәтеп) | |
| 15. | Арендаторлар, ссуда алучылар саны | |
| 16. | Күчемсез милектән файдалану нәтиҗәлелеген арттыру, хуҗалык әйләнешенә җәлеп итү буенча тәкъдимнәр яисә аны алга таба эксплуатацияләү өчен яраксызлыкка китергән сәбәпләрне күрсәтү | |
| 17. | Хисап елында күчемсез милек объектыннан файдаланудан алынган керемнәр суммасы, сум (муниципаль учреждениеләр өчен), шул исәптән: | |
| | - мөлкәтне арендага бирүдән | |
| | - муниципаль учреждение уставында каралган башка түләүле хезмәтләр күрсәтүдән | |
| | - гамәлгә куючы тарафыннан расланган муниципаль йөкләмә нигезендә хезмәтләр күрсәтүгә субсидияләр суммасы | |
| 18. | Хисап елында күчемсез милек объектыннан файдаланудан алынган керемнәр суммасы, сум (муниципаль предприятиеләр өчен), шул исәптән: | |
| | - мөлкәтне арендага бирүдән | |
| | - муниципаль предприятие уставында каралган башка коммерция эшчәнлегеннән | |
| 19. | Күчемсез милек объектын карап тотуга юнәлдерелгән чыгымнар суммасы, сум, шул исәптән: | |
| | күчемсез милеккә салым түләү | |
| | арендага бирелгән күчемсез милек объектын карап тотуга түләнмәгән чыгымнар (коммуналь һәм гомуми эксплуатация чыгымнары) | |

| | | |
|---|---|---|
| | түләүсез файдалануга бирелгән күчемсез милек объектын карап тотуга түләнмәгән чыгымнар (коммуналь һәм гомуми эксплуатация чыгымнары) | |
| | устав эшчәнлеген алып бару өчен файдаланыла торган күчемсез милек объектын карап тотуга чыгымнар | |

Формада күрсәтелгән мәгълүматларны раслыйбыз:

Оешма (объектны балансга тотучы) җитәкчесе :

____________________ __________________ /____________________/

(вазыйфа) (имза) (Ф.И.А.и.)

Оешманың (объектны балансга тотучының) баш бухгалтеры:

____________________ __________________ /____________________/

(вазыйфа) (имза) (Ф.И.А.и.)

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Г.К. Әхмәтова

Яр Чаллы шәһәренең күчемсез
милек объектларыннан файдалану
нәтиҗәлелеген бәяләү методикасына
2 нче кушымта

«___» _________ 20__ елга торышы буенча
күчемсез милек объектының арендаторы (ссуда алучы), субарендаторы турында
мәгълүматлар

_______________________________________________
(оешманың (күчемсез милекне балансста балансста тотучының) тулы исеме)

_______________________________________________
(күчемсез милекнең исеме)

_______________________________________________
(күчемсез милекнең урнашу урыны)

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Арендаторның (ссуда алучының) тулы һәм кыскартылган исеме | |
| 2. | Юридик адресы (тулы) | |
| 3. | Гамәлгә куючы турында мәгълүматлар (тулы исеме, юридик адресы) | |
| 4. | Җитәкченең вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме (тулысынча), | |
| 5. | Җитәкченең телефоны, e-mail | |
| 6. | Аренда (түләүсез файдалану) шартнамәсе төзү датасы һәм номеры | |
| 7. | Аренда (түләүсез файдалану) шартнамәсенә өстәмә килешү датасы һәм номеры | |
| 8. | Аренда (түләүсез файдалану) шартнамәсенең гамәлдә булу срогы | |
| 9. | Аренда (түләүсез файдалану) хокукын дәүләт теркәвенә алу датасы һәм номеры | |
| 10. | Биләнә торган бүлмәләрнең гомуми/файдалы мәйданы, кв.м. | |
| 11. | Бүлмәләрдән файдалану максаты | |
| 12. | Субарендаторлар саны | |
| 13. | Субарендага бирелгән гомуми мәйдан кв.м. | |
| 14. | Айлык аренда түләве күләме, сум | |

Формада күрсәтелгән мәгълүматларны раслыйбыз:

Оешма (объектны балансста тотучы) җитәкчесе :

______________________ ____________________ /_______________________/
(вазыйфа) (имза) (Ф.И.А.и.)

Оешманың (объектны балансста тотучының) баш бухгалтеры:

______________________ ____________________ /_______________________/
(вазыйфа) (имза) (Ф.И.А.и.)

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Яр Чаллы шәһәренең күчемсез
милек объектларыннан файдалану
нәтиҗәлелеген бәяләү методикасына
3 нче кушымта

«_____» _________ 20____ елга торышы буенча
муниципаль казна, бюджет, автономияле учреждениеләр тарафыннан
күчемсез милек объектларыннан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләрнең
зурлыклары

| № т/б | Күрсәткечнең исеме | Үлчәү берәмлеге | 20___ (алдагы ел) (факт) | 20___ (хисап елы) (факт) |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Күчемсез милек объектларының саны | берәмлек | | |
| 2. | Күчемсез милек объектларының гомуми мәйданы, шул исәптән: | кв.м | | |
| 2.1. | Арендага бирелгән күчемсез милек объектлары | кв.м | | |
| 2.2. | Түләүсез файдалануга бирелгән күчемсез милек объектлары | кв.м | | |
| 2.3. | Устав эшчәнлеген алып бару өчен файдаланыла торган күчемсез милек объектлары | кв.м | | |
| 3. | Күчемсез милек объектларыннан файдаланудан алынган керемнәр суммасы, шул исәптән: | мең сум | | |
| 3.1. | арендага бирүдән | мең сум | | |
| 3.2. | муниципаль учреждение уставында каралган башка түләүле хезмәтләр күрсәтүдән | мең сум | | |
| 3.3. | - гамәлгә куючы тарафыннан раслаган муниципаль йөкләмә нигезендә хезмәтләр башкаруга субсидияләр суммасы | мең сум | | |
| 4. | Күчемсез милек объектларын карап тотуга юнәлдерелгән чыгымнар суммасы, шул исәптән : | мең сум | | |
| 4.1. | мөлкәткә салым түләү | мең сум | | |
| 4.2. | арендага бирелгән күчемсез милек объектын карап тотуга түләнмәгән чыгымнар (коммуналь һәм гомуми эксплуатация чыгымнары) | мең сум | | |
| 4.3. | түләүсез файдалануга бирелгән күчемсез милек объектын карап тотуга түләнмәгән чыгымнар (коммуналь һәм гомуми эксплуатация чыгымнары) | мең сум | | |
| 4.4. | устав эшчәнлеген алып бару өчен файдаланыла торган күчемсез милек объектын карап тотуга чыгымнар | мең сум | | |
| 5. | Күчемсез милек объектларының гомуми баланс (калдык) бәясе, шул исәптән: | мең сум | | |
| 5.1. | арендага бирелгән күчемсез милек объектлары | мең сум | | |
| 5.2. | түләүсез файдалануга бирелгән күчемсез милек объектлары | мең сум | | |
| 5.3. | устав эшчәнлеген алып бару өчен файдаланыла торган күчемсез милек объектлары | мең сум | | |
| 6. | Төп чараларның тузуы | % | | |
| 7. | Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән (эшләр башкарудан) алынган акчалар хисабына төп средстволарны яңадан торгызуга юнәлдерелгән сумма | мең сум | | |

Формада күрсәтелгән мәгълүматларны раслыйбыз:

Оешма (объектны баланста тотучы) җитәкчесе :

| ______________________ | ____________________ | /________________________/ |
| --- | --- | --- |
| (вазыйфа) | (имза) | (Ф.И.А.и.) |

Оешманың (объектны баланста тотучының) баш бухгалтеры:

| ______________________ | ____________________ | /________________________/ |
| --- | --- | --- |
| (вазыйфа) | (имза) | (Ф.И.А.и.) |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Яр Чаллы шәһәренең күчемсез
милек объектларыннан файдалану
нәтиҗәлелеген бәяләү методикасына
4 нче кушымта

«___» _________ 20___ елга торышы буенча
муниципаль казна, унитар предприятиеләр тарафыннан
күчемсез милек объектларыннан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең
зурлыклары

| № т/б | Күрсәткечнең исеме | Үлчәү берәмлеге | 20___ (алдагы ел) (факт) | 20___ (хисап елы) (факт) |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Күчемсез милек объектларының саны | берәмлек | | |
| 2. | Күчемсез милек объектларының гомуми мәйданы, шул исәптән: | кв.м | | |
| 2.1. | арендага бирелгән күчемсез милек объектлары | кв.м | | |
| 2.2. | түләүсез файдалануга бирелгән күчемсез милек объектлары | кв.м | | |
| 2.3. | устав эшчәнлеген алып бару өчен файдаланыла торган күчемсез милек объектлары | кв.м | | |
| 3. | Күчемсез милек объектларыннан файдаланудан алынган керемнәр суммасы, шул исәптән: | мең сум | | |
| 3.1. | күчемсез милек объектларын арендага бирүдән | мең сум | | |
| 3.2. | муниципаль предприятие уставында каралган башка коммерция эшчәнлегеннән | мең сум | | |
| 4. | Күчемсез милек объектларын карап тотуга юнәлдерелгән чыгымнар суммасы, шул исәптән: | мең сум | | |
| 4.1. | мөлкәткә салым түләү | мең сум | | |
| 4.2. | арендага бирелгән күчемсез милек объектын карап тотуга түләнмәгән чыгымнар (коммуналь һәм гомуми эксплуатация чыгымнары) | мең сум | | |
| 4.3. | түләүсез файдалануга бирелгән күчемсез милек объектын карап тотуга түләнмәгән чыгымнар (коммуналь һәм гомуми эксплуатация чыгымнары) | мең сум | | |
| 4.4. | устав эшчәнлеген алып бару өчен файдаланыла торган күчемсез милек объектын карап тотуга чыгымнар | мең сум | | |
| 5. | Күчемсез милек объектларының гомуми баланс (калдык) бәясе, шул исәптән: | мең сум | | |
| 5.1. | арендага бирелгән күчемсез милек объектлары | мең сум | | |
| 5.2. | түләүсез файдалануга бирелгән күчемсез милек объектлары | мең сум | | |
| 5.3. | устав эшчәнлеген алып бару өчен файдаланыла торган күчемсез милек объектлары | мең сум | | |
| 6. | Төп чараларның тузуы | % | | |
| 7. | Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән (эшләр башкарудан) алынган акчалар хисабына төп средстволарны яңадан торгызуга юнәлдерелгән сумма | мең сум | | |

Формада күрсәтелгән мәгълүматларны раслыйбыз:

Оешма (объектны балансста тотучы) җитәкчесе :

________________________ _____________________ /________________________/

(вазыйфа) (имза) (Ф.И.А.и.)

Оешманың (объектны балансста тотучының) баш бухгалтеры:

________________________ _____________________ /________________________/

(вазыйфа) (имза) (Ф.И.А.и.)

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Яр Чаллы шәһәренең күчемсез
милек объектларыннан файдалану
нәтиҗәлелеген бәяләү методикасына
5 нче кушымта

«___» _________ 20____ елга торышы буенча
муниципаль учреждениеләр тарафыннан күчемсез милек объектларыннан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең җыелма зурлыклары

_______________________________________________
(тармак органының исеме)

| Исеме | күчемсез милек объектларының саны, берәмлекләр | Күчемсез милекнең гомуми мәйданы, кв.м. | | | | Күчемсез милек объектларын файдаланудан алынган керемнәр суммасы (мең сум) | | | | Күчемсез милек объектларын карап тотуга юнәлдерелгән чыгымнар суммасы (мең сум) | | | | | күчемсез милекнең гомуми баланс (калдык) бәясе (мең сум), шул исәптән: | арендага бирелгән күчемсез милек объектлары | түләүсез файдалануга бирелгән күчемсез милек объектлары | устав эшчәнлеген алып бару өчен файдаланыла торган күчемсез милек объектлары | Төп чараларның тузуы, % | Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән (эшләр башкарудан) алынган акчалар хисабына төп средстволарны яңадан торгызуга юнәлдерелгән сумма, мең сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | барлыгы | арендага бирелгән | түләүсез файдалануга бирелгән | устав эшчәнлеген алып бару өчен файдаланыла торган | барлыгы | күчемсез милек объектларын арендага бирүдән | уставта каралган башка түләүле хезмәтләр күрсәтүдән | Муниципаль йөкләмәне үтәү өчен субсидияләр | барлыгы | мөлкәткә салым түләү | Арендага бирелгән күчемсез милек объектларын карап тотуга түләнмәгән чыгымнар | Түләүсез файдалануга бирелгән күчемсез милек объектларын карап тотуга түләнмәгән чыгымнар | Устав эшчәнлеген алып бару өчен күчемсез милек объектларын карап тотуга чыгымнар | | | | | | |
| 1 | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 |
| Казна учреждениесе | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Алдагы ел факт) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Хисап елы (факт) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Хисап елыннан соң килә торган ел (фараз) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Казна учреждениеләре буенча барлыгы | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Алдагы ел (факт) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Хисап елы (факт) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Хисап елыннан соң киләчәк торган ел (фараз) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Бюджет учреждениесе | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Алдагы ел (факт) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Хисап елы (факт) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Хисап елыннан соң килә торган ел (фараз) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Бюджет учреждениеләре буенча барлыгы | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Алдагы ел (факт) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Хисап елы (факт) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Хисап елыннан соң килә торган ел (фараз) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Автономияле учреждение | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Алдагы ел (факт) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Хисап елы (факт) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Хисап елыннан соң килә торган ел (фараз) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Автономияле учреждениеләр буенча барлыгы | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Алдагы ел (факт) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Хисап елы (факт) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Хисап елыннан соң килә торган ел (фараз) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Муниципаль учреждениеләр буенча барлыгы | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Алдагы ел (факт) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Хисап елы (факт) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Хисап елыннан соң килә торган ел (фараз) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе




Г.К. Әхмәтова

Яр Чаллы шәһәренең күчемсез
милек объектларыннан файдалану
нәтиҗәлелеген бәяләү методикасына
6 нчы кушымта

«___» _________ 20____ елга торышы буенча
муниципаль предприятиеләр тарафыннан күчемсез милек объектларыннан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең җыелма зурлыклары

_______________________________________________
(тармак органының исеме)

| Исеме | күчемсез милек объектларының саны, берәмлекләр | Күчемсез милек объектларының гомуми мәйданы, кв.м. | | | | Күчемсез милек объектларын файдаланудан алынган керемнәр суммасы (мең сум) | | | Күчемсез милек объектларын карап тотуга юнәлдерелгән чыгымнар суммасы (мең сум) | | | | | күчемсез милекнең гомуми баланс (калдык) бәясе (мең сум), шул исәптән: | арендага бирелгән күчемсез милек объектлары | түләүсез файдалануга бирелгән күчемсез милек объектлары | устав эшчәнлеген алып бару өчен файдаланыла торган күчемсез милек объектлары | Топ чараларның тузуы, % | Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән (эшләр башкарудан) алынган акчалар хисабына топ средстволарны яңадан торгызуга юнәлдерелгән сумма, мең сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | барлыгы | Арендага бирелгән күчемсез милек объектлары | Түләүсез файдалануга бирелгән күчемсез милек объектлары | Устав эшчәнлеген алып бару өчен файдаланыла торган күчемсез милек объектлары | барлыгы | күчемсез милек объектларын арендага бирүдән | муниципаль предприятие уставында каралган башка коммерция эшчәнлеге күрсәтүдән | барлыгы | мөлкәткә салым түләү | Арендага бирелгән күчемсез милек объектларын карап тотуга түләнмәгән чыгымнар | Түләүсез файдалануга бирелгән күчемсез милек объектларын карап тотуга түләнмәгән чыгымнар | Устав эшчәнлеген алып бару өчен күчемсез милек объектларын карап тотуга чыгымнар | | | | | | |
| 1 | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
| Казна предприятиеләре | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Алдагы ел (факт) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Хисап елы (факт) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Хисап елыннан соң килә торган ел (фараз) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Казна предприятиеләре буенча барлыгы | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Алдагы ел (факт) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Хисап елы (факт) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Хисап елыннан соң киләә торган ел (фараз) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Унитар предприятиеләр | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Алдагы ел (факт) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Хисап елы (факт) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Хисап елыннан соң килә торган ел (фараз) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Муниципаль предприятиеләр буенча барлыгы | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Алдагы ел (факт) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Хисап елы (факт) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Хисап елыннан соң килә торган ел (фараз) | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова

Яр Чаллы шәһәренең күчемсез
милек объектларыннан файдалану
нәтиҗәлелеген бәяләү методикасына
7 нче кушымта

«_____» _________ 20____ елга торышы буенча
муниципаль казна милке объектларыннан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең зурлыклары

| №<br>т/б | Күрсәткечнең исеме | Үлчәү берәмлеге | 20___<br>(алдагы ел)<br>(факт) | 20___<br>(хисап елы)<br>(факт) |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Күчемсез милек объектларының саны | берәмлек | | |
| 2. | Күчемсез милек объектларының гомуми мәйданы, шул исәптән: | кв.м | | |
| 2.1. | арендага бирелгән күчемсез милек объектлары | кв.м | | |
| 2.2. | түләүсез файдалануга бирелгән күчемсез милек объектлары | кв.м | | |
| 3. | Күчемсез милек объектларын арендага бирүдән алынган керемнәр суммасы | мең сум | | |
| 4. | Күчемсез милек объектларын карап тотуга юнәлдерелгән чыгымнар суммасы, шул исәптән : | мең сум | | |
| 4.1. | мөлкәткә салым түләү | мең сум | | |
| 4.2. | арендага бирелгән күчемсез милек объектларын карап тотуга чыгымнар (коммуналь һәм гомуми эксплуатация) | мең сум | | |
| 4.3. | түләүсез файдалануга бирелгән күчемсез милекне карап тотуга чыгымнар (коммуналь һәм гомуми эксплуатация чыгымнары) | мең сум | | |
| 5. | Күчемсез милек объектларының гомуми баланс (калдык) бәясе, шул исәптән: | мең сум | | |
| 5.1. | арендага бирелгән күчемсез милек объектлары | мең сум | | |
| 5.2. | түләүсез файдалануга бирелгән күчемсез милек объектлары | мең сум | | |

Башкарма комитетның
җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр
идарәсе башлыгы ____________________ /________________________/
(имза) (Ф.И.А.и)

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова